РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Ленина, 44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 22.04.2019 г. № 4

Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең
муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү
турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларда үзгәрешләр мониторингы үткәрү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Уставына таянып, Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турында теркәлгән Нигезләмәне расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенә:

үз нормалар иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы затлар итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең Уставы нигезендә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының һәм Каенлы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Каенлы авыл җирлеге
башлыгы Ф.М. Набиуллин

Каенлы авыл җирлеге
Советының
2019 елның 22 апрелендәге
4 номерлы карарына
кушымта

# Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр мониторингы (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль актларны кабул итүне (бастыруны), үзгәртүне яки көчен югалткан дип тануны (юкка чыгаруны) тәэмин итү өчен мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенчагамәлгә ашырыла торган системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлеген күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3.Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргәндә Түбән Кама муниципаль районы Советы аппаратының хокук бүлеге һәм муниципаль берәмлекнең башка җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итәләр.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып торалар:

федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында муниципаль актларны кабул итү, үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану ихтыяҗларын ачыклау;

муниципаль актларда фикер каршылыкларын, каршылыкларны, җитешсезлекләрне бетерү, хокукый җайга салуда кабатлау;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актларда коррупциячел факторларны ачыклау;

гамәлдә файдаланмаган яисә кирәк булмаган (актуальлеген югалткан) муниципаль актларның яисә аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук куллану нәтиҗәлелеген арттыру;

муниципаль актларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген киметә торган факторларны ачыклау;

муниципаль актларның үтәлешенә җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан контрольне гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

нормалар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6.Мониторинг үз эченә үзгәрешләрне җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләүне ала:

федераль конституция законнары, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актлары;

Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актлар;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Каенлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Уставы, муниципаль хокукый актлар.

7. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып торалар:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салуның билгеле өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

муниципаль актларны камилләштерү яки кимчелекләре турында гаммәви мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән үз эченә алган:

Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга каратаТатарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

билгеләнгән тәртиптә аны үткәрүгә вәкаләтле затлар тарафыннан әзерләнгән муниципаль актларга коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләрнең, семинарларның, җәмәгать тыңлавының, иҗтимагый фикер алышуларның һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнештә аларның компетенциясе мәсьәләләре буенча мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатларында, эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг анализ ясау аша башкарыла:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актлар;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актлары (суд практикасы);

прокурор җавап кайтару актлары.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән нормалар

иҗат итү эше нәтиҗәләрен теркәп бару максатларында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 30 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында» карары нигезендә башкарыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (контрактлар, аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле күрсәтелгән мөмкинлекләр булганда):

белешмә хокукый системаларда закон һәм башка норматив хокукый актларга тикшереп торуга куелган үзгәрешләр турында мәгълүмат керү;

белешмә хокукый системаларны хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар тасмалары мәгълүматы керү;

муниципаль актларда ачыкланган законнарга туры килмәү турында «Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы мәгълүматы керү.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастыруны), үзгәртүне яки көчен югалткан дип тануны (юкка чыгаруны) тәэмин итү өчен мониторинг гамәлгә ашырганда, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән бергә түбәндәге критерийлар буенча муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

муниципаль актларны кабул итү (бастыру) зарурлыгы билгеләнгән зур юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булу;

муниципаль акт чыгарганда җирле үзидарә органы компетенциясе чикләрен үтәү;

муниципаль актта ришвәтчелек факторлары булу;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда тулылык;

хокук нормалары фикер каршылыклары;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

аны кулланганда муниципаль акт нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда, хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр кылу (гамәл кылмау);

норматив хокукый актларны куллану практикасы булу;

норматив хокукый актларны куллануның бертөрле практикасының булмавы;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризаларның булуы (саны) һәм эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турындагы закон көченә кергән суд актлары һәм аларны кабул итү нигезләре булу (саны).

13. Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль актларга үзгәрешләр кертүгә китерә торган федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр монито-

рингы нәтиҗәләре буенча ачыкланган очракта:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында тиешле муниципаль актлар проектлары эшләнә;

муниципаль актларны зуррак юридик көч актлары белән тәңгәлләштерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14. Муниципаль актларны үзгәртү зарурлыгына китерә торган федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг, әлеге пунктның өченче абзацында каралган очраклардан тыш, федераль яки республика актын чыгарганнан соң 30 көн эчендә уздырыла.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре торса, шулай ук прокуратура мәгълүматы, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларда каралганпрокурор җавабы актларыннан тыш, мониторинг алар кергәнннән соң 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт кабул итү, әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгән мизгелдән ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисаптан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә алырга тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрү башкаручылары турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрү чоры турында мәгълүмат;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасы, мониторинг үткәрү нигезләре.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә алырга мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актларны кабул итү, юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камил-

ләштерүгә юнәлдерелгән мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабат кабул ителгән муниципаль актлар законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрелә.

Әлеге регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган анда булмаган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый иҗат итү эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук муниципаль актларны җирле үзидарә органнары карамагындагы тиешле хокукый җайга салу өлкәсендә федераль һәм республика законнарына вакытында туры китерү өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җаваплылык тоталар.

20. Тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлләр (гамәл кылмау) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплылык тоталар.

Каенлы авыл җирлеге
башлыгы Ф.М. Набиуллин